| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.06.2025 ел Алабуга шәһәре № 440

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының аерым җирле үзидарә органнары Нигезләмәләрен раслау турында» 2011 елның 28 февралендәге 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Алабуга муниципаль районы Советы:

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2011 елның 28 февралендәге 72 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. IV бүлекне «Палата хокуклары һәм бурычлары» пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«4.1.11. Үз функцияләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары Р.З. Шиһапов